# ТАТАР ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ ЭЧКЕ РЕСУРСЛАР ХИСАБЫНА ҮСЕШЕ (XX ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫ)

© Р.С.Нурмөхәммәтова

Статья посвящена исследованию развития лексики татарского литературного языка первой половины XX века. В ней рассматриваются такие внутренние ресурсы развития лексики, как словообразование, обогащение словарного состава языка путем расширения значений в слове, калькирование, использование диалектной лексики. Выводы аргументируются материалами татарско-русских словарей исследуемого периода.

Татар теле лексикасының үсеше юллары, аның төрле чорлардагы хәле әлегә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән өлкәләрнең берсен тәшкил итә. Соңгы елларда татар тел белемендәге бу проблемага күп галимнәр игътибар итә башлады. Лексиканың үсешенә караган фикерләр Ф.Ә.Ганиев, М.З.Зәкиев, Ф.С.Сафиуллина, В.Х.Хаков кебек галимнәребезнең хезмәтләрендә инде шактый еллардан чагылыш тапса да, тирәнтен фәнни тикшеренүләр 90-нчы еллардан күренә башлады, шактый гына диссертацияләр, монографияләр дөнья күрде. Тик шулай да зур сәяси-тарихи үзгәрешләргә бай булган XX гасырның беренче яртысы тел белгечләре тарафыннан өйрәнүне таләп иткән бер өлкә булып кала бирде. Бу хезмәт нәкъ менә шушы чордагы татар теле лексикасы үсешен барлауны күздә тота, аның актуальлеге шуның белән билгеләнә дә. Тикшеренүнең фәнни яңалыгы – тел лексикасының үсешен, беренчеләрдән булып, моңарчы өйрәнелмәгән чыганаклар – татарча-русча сүзлекләр буенча күзәтүдән гыйбарәт. Хезмәтнең максаты – XX гасырның беренче яртысында басылган татарча-русча сүзлекләрдә тупланган фактик материалга нигезләнеп, татар теле лексикасының үз ресурслары җирлегендә үсеш юлларын ачыклау.

Телнең үсеше һәм үзгәреше иҗтимагый-тарихи шартлар үзгәрү һәм бер-берсенә тәэсир итүче телләрнең үзенчәлеге белән билгеләнә. Телнең үсеше – аның сүзлек составы баю, сүзләрнең билгеле бер төшенчәләрне белдерү өчен ныгуы, аның грамматик системасы камилләшү дигән сүз [1, с.19].

Телнең үсеше турында сөйләгәндә, лексикадагы үзгәрешләргә күбрәк игътибар итәләр. Беренче карашка телнең үсешен аның лексик материалы нигезендә күзәтү барыннан да җиңел кебек. Лексика өлкәсендә тел, чыннан да, хәрәкәтчәнрәк. Кешелекнең матди һәм рухи тормышы теләсә кайсы телнең сүзлек составында чагылыш таба. Бер төркем сүзләр үткәндә кала, искерә яки бөтенләй онытыла, икенчеләре исә, керсенчә, яңадан ясала, телне баета, аның кулланылыш чикләрен киңәйтә [2, с.41].

Лексика, телнең лексик фонды, бердәм тел системасының состав өлеше буларак, аның калган якларыннан – фонетика, морфология, синтаксистан кискен аерыла. Бу аерымлык аның турыдан-туры чынбарлыкка йөз тотуыннан гыйбарәт. Шуңа күрә җәмгыять тормышындагы барлык үзгәрешләр, барыннан да элек лексикада күренә [3, с.75].

Сүзлек составының үзгәрүенә китерә торган процессларның катлаулы һәм күптөрле булуы кайбер гомуми закончалыкларны катгый билгеләүне таләп итә. Нәкъ менә лексика өчен моны эшләүнең катлаулы булуы аңлашыла. Әгәр лексикада бара торган үзгәрешләр тышкы факторлар аркасында гына була икән, димәк, лексикология чиксез күләмдәге фактлар һәм фаразлар җыелмасыннан гыйбарәт дигән сүз, ә ул фараз-факторларны "тел белеме" дәрәҗәсендә гомумиләштерергә дә, системалаштырырга да мөмкин түгел [4, с.5]. Шулай да лексикология фәне тарихында телнең сүзлек байлыгын арттыру юлларын билгеләргә омтылышлар булган һәм булып тора.

Әдәби телнең формалашу процессы – идарә итеп булмый торган күренеш. Телгә аңлы рәвештә тәэсир итәргә тырышуларның ахырына кадәр һәм тулысынча тормышка ашырыла алмауларын тарих тулысынча исбатлады. Язу традициясе көчлерәк булган саен, әдәби тел белән "җитәкчелек итү" шулкадәр авыррак була. Сүзлекләр һәм грамматикалар исә телдә табигый рәвештә бара торган һәм җитди үзгәрешләрне чагылдыралар [5, с.143].

Сүзлекләр татар теленең бердәм лексик нормалары эшләнүенең озын һәм дәвамлы процессын ачык күрсәтәләр. Татар әдәби теленең төп лексикасын, билгеле бер күләмдә архаизмнар, тарихи сүзләр, терминнар һәм лексик диалектизмнарны җыйнап биргән хәлдә, алар татар тел белемендә дә кыйммәтле өлеш кертәләр. Әлеге хезмәтләр татар теленең лексикасын фәнни яктан өйрәнү өчен ышанычлы чыганак булып торалар.

Бу мәкаләдә XX гасырның беренче яртысында татар теле лексикасының торышын тикшерү өчен сүзлекләргә мөрәҗәгать итү дә юкка түгел.

Бер генә телнең, шул исәптән татар теленең дә сүзлек байлыгы кинәт кенә, берьюлы барлыкка килмәгән. Ул озын, тарихи юл үткән, күп еллар, гасырлар дәвамында үскән, формалашкан. Еллар үтү белән яңа сүзләр барлыкка килгән, яшәп килгән сүзләрнең мәгънәләре киңәйгән. Бу процесс халыкның сәяси, икътисадый һәм мәдәни тормышы белән бәйләнештә барган [6, б.204].

Хәзерге татар теле лексикасын бай һәм киң әтрафлы сүзләр системасы һәм аларның мәгънәләре тәшкил итә. Аның лексик байлыгы зур үсеш алган телләрдән берничек тә калышмый. Анда төрле структураларга һәм стильләргә караган йөзләрчә мең сүзләр бар.

Лексика үсешенең юллары тел белемендә төгәл генә ачыкланып бетмәгән. Ф.Ә.Ганиев, Н.С.Валгина, К.М.Мусаев, Ш.А.Рамазанов, Ф.С.Сафиуллина, В.Х.Хаков һ.б. хезмәтләрендә бу мәсьәләнең күп кенә аспектлары чагылыш таба. Бу мәкаләдә әлеге галимнәрнең фикерләре нигез итеп алынып, XX гасырның беренче яртысында татар теле лексикасының эчке ресурслар нигезендә үсүен түбәндәге юнәлешләрдә карау максат итеп куела:

1) телнең үз чаралары белән сүзләр ясау;
2) сүзләрнең мәгънәләре киңәю һәм конкретлашу;
3) калькалаштыру;
4) телнең диалекталь сүзләр хисабына үсеше.

Лексика үсешенең беренче юлы бик борынгыдан килә. Һәрбер тел иң беренче чиратта үзенең сүз ясау мөмкинлекләре хисабына үсә. Татар телендә яңа сүзләр ясауда иң актив юл – кушымчалау ысулы. Яңа берәмлекләр шулай ук сүзләр кушылу, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе нигезендә дә барлыкка киләләр.

Татар теленең яңа сүз ясый торган чаралары, аның грамматик формантлары кебек, бик тотрыклылар. Хәзерге татар теленә хас сүз ясау чаралары һәм ысуллары борынгы татар теле истәлекләрендә дә сакланып калган [6, б.204]. Татар теленең сүз ясау чараларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдә аерып күрсәтелгән продуктив кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр XX гасырның беренче яртысы татарча-русча сүзлекләрендә дә бик күп, аларның белдергән мәгънәләре бүгенге көндәгедән аерылмый диярлек.

XX гасырның беренче яртысы – җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләр, фән-техниканың алга китүе, хуҗалык итү формаларының камилләшүе, әдәбият-сәнгатьнең үсеше һ.б. белән характерлана торган чор. Бу үзгәрешләргә бәйле рәвештә туган яңа төшенчәләрне атау ихтыяҗы барлыкка килә, телдә булган байлык кына бу ихтыяҗларны канәгатьләндерә алмый, яңа сүзләр зарурлыгы туа һәм телнең барлык мөмкинлекләре эшкә җигелә. Иң беренче чиратта сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә фән-техника, халык хуҗалыгына караган атамалар, ягъни **исем** сүз төркеменә караган берәмлекләр барлыкка килә. Яңа сүзләр ясауда түбәндәге кушымчалар актив файдаланыла: **-гыч/-геч** (-кыч/-кеч): *агызгыч* – пипетка; *арындыргыч* – сортивовка; *әйләндергеч* – двигатель; *бастыргыч* – пресс; *бөркегеч* – пульверизатор; *җилләткеч* – опохало, веер, вентилятор; *йөрткеч* – привод, *аклагыч* – оправдательный документ; *белдергеч* – руководство, по которому узнается дело, по которому делается дело; *күчергеч* – пропись, копия, образчик һ.б.; **-ма/-мә**: *борма* – поворот, зигзаг, винт, спираль; *бөгелмә* – загиб; *йөкләнмә* – обязательство, повинность; *казылма* – выбоина, яма на дороге, һ.б.; **-ыш/-еш**: *агыш* – течение времени; *барыш* – ход, течение, направление; *күчеш* – переход, *бөгеш* – складка одежды, платья; *гәүдәләнеш* – выражение; *йогыш* –зараза, инфекция; *казаныш* – успех; *куелыш* – постановка); *күтәрелеш* – восстание (*кырылыш* – бойня, избиение; *сузылыш* – пространство; *сыйдырыш* – емкость; *чиртеш* – щелчок һ.б.; **-лык/-лек**: *җиткелек* – достаточность; *төрлек* – части речи в грамматике; *буяучылык* – ремесло маляра һ.б. Сыйфат ясауда түбәндәге кушымчалар актив: **-лы/-ле** һәм аңа капма каршы мәгънәле **-сыз/-сез** кушымчасы: *катмарлы* – махровый (о цветке); *күчемсез* – стационарный; *табышлы* – прибыльный; *табышсыз* – бесприбыльный һ.б.; **-малы/-мәле**: *асылмалы* – висячий; *бүленмәле* – делимый, способный делиться; *үлчәнмәле* – весомый, соизмеримый һ.б.; **-чан/-чән**: *ачучан* – вспыльчивый, сердитый; *даучан* – сутяга, спорщик; *сагышчан* – задумчивый; *сыйчан* – гостеприимный һ.б. Фигыль ясалышына килгәндә, бу чорда да хәзерге татар теленең актив кушымчалары һәм хәзерге көндә бик үк продуктив булмаган кушымчалар белән ясалган йөзләрчә фигыльләр теркәлгән: **-лан/-лән**: *ачулану*, *җимешләнү, икеләнү, йөрәкләнү* һ.б.; **-ылда/-елдә** һәм **-да/-дә:** *бызылдау*, *жуылдау, какылдау*, *лыбырдау* һ.б.; **-сын/-сен**: *азсыну*, *кимсенү, тарсыну*, *юксыну, ятсыну* һ.б.

Сүзлекләрдә теркәлгән кушма сүзләр арасында исемнәр шулай ук зур күпчелекне тәшкил итә, **исем + исем тибы** аеруча еш күзәтелә, мондый тезмәләр беренче һәм икенче төр изафәгә нигезләнеп ясалганнар. Мәсәлән, ***беренче төр изафә*** буенча барлыкка килгән берәмлекләр: *алкушымча* – приставка (грам.); *ата каптырма* – крючок в петле; *баба тел* – праязык; *комкорсак* – пескарь; *көнүзәк* – злободневный; *су борчасы* –

дафния; *ташбаш* – головач, бычок, пескарь; *төббаш* – комел; *түгәрәк кыегы* – сектор (круга) һ.б.

***Икенче төр изафәләр***дә бәйләүче чара *-ы* тартым кушымчасы һәм сүз тәртибе: *аю балыгы* – тюлень; *диңгез мәчесе* – котик; *диңгез өермәсе* – тайфун; *җир җенесләре* – горные породы; *җир күмере* – каменный уголь; *кием калыбы* – манекен; *очкылык үләне* – икотник; *су сыеры* – буйвол; *суган гөле* – нарцисс; *фил балыгы* – кит һ.б. *Исем + исем* тибы белән ясалган кушма сүзләр арасында биология, ботаника, зоология фәннәренә караган терминнар бик күп булуы күзәтелә.

**сыйфат + исем тибын**дагы кушма сүзләр татар телендә күп түгел, мондый төзелештәге кушма сүзләр нигезләр кушылу юлы белән түгел, ә ирекле сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү юлы белән барлыкка килгәннәр, шунлыктан әлеге сүзләрнең ясалыш алымын билгеләү шактый кыен. Алар арасында да терминнар зур урын алып торалар. Мәсәлән, *ала миләүшә* – анютины глазки; *алгышарт* – предпосылка; *җәенке почмак* – тупой угол; *җирле тел* – диалект, наречие; *кызылтамыр* – кузмичева трава; *сасы бака* – жаба; *төче авыруы* – сахарная болезнь; *убырлы карт* – колдун; *урә кыр* – катет һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, шактый уңышлы терминнар гамәлдә булган, аларның күбесе хәзерге телдә дә кулланыла. Арада белдергән мәгънәләре бераз аерылганнары да бар: *гөберле бака* – лягушка лексемасы хәзер бакаларның бер төрен атаучы *жаба* сүзенә туры килә; *куш җәя, куш тырнак* икесе дә бер мәгънәне белдергән, ләкин бу терминнарының *куштырнак* дигәне активлашып киткән. Хәзерге вакытта ярымкалька һәм алынма сүз белән белдерелә торган *агглютинатив телләр*, *потенциал* кебек төшенчәләрне узган гасыр урталарындагы кебек *ялганмалы телләр*, *яшерен көч* дигән терминнар белән атау хәзерге татар теле өчен дә бик кулай булыр иде.

Телнең теләсә кайсы чордагы үсешен сүзлек составындагы үзгәрешләр, лексик берәмлекләрнең саны арту-киму генә билгеләми. Сүзләрнең мәгънәләре киңәю яки конкретлашуына бәйле үзгәрешләр дә телнең баюына һәм камилләшүенә китерә. Җәмгыятьтә туган яңалыклар һәрвакытта да яңа сүзләр ясауны таләп итми. Телдә моңарчы яшәгән сүзләрнең мәгънә эчтәлекләрен үзгәртү юлы белән дә яңа төшенчәләрне атарлык берәмлекләр барлыкка килергә мөмкин. Бу – табигый һәм телнең зур эчке мөмкинлекләрен күрсәтүче факт. Күренекле тел галиме Ш.Рамазанов сүзләре белән әйткәндә, "тел бит яңа төшенчәләр өчен һәрвакыт яңа сүзләр ясап тормый. Моның һәрвакыт кирәге дә булмый. Тел хәзинәсендәге әзер сүзләр белән файдаланырга туры килә. Кайбер сүзләргә яңа мәгънә салына, кайберләренең мәгънә түгәрәге тарайтыла, ә кайберләренең кулланылыш сферасы, мәгънә түгәрәге киңәеп китә" [7, б.92].

Яңа сүзләр барлыкка килү яңа күренеш, төшенчәләр, техника һәм мәдәниятнең, кешелек белемнәренең артуы һәм киңәюе белән аерылгысыз бәйләнештә булса да, барлыкка килгән һәм кулланылыштан чыккан берәмлекләр саны, алда әйтелгән сәбәпләр аркасында мәгънәләрен үзгәрткән лексемалар җирлегендә алай ук күп түгел. Еш кына бер мәгънәле сүз, яңа мәгънәләр белән тулыланып, полисемантик сүзгә әйләнә. Лексиканың камилләшүе сүзлек байлыгының сан ягыннан артуына гына кайтып калмый, лексиканың сыйфат ягыннан үсүе дә зур әһәмияткә ия [2, с.41-52]. Әлегә кадәр гамәлдә булган сүзләрнең мәгънәләре арту телнең сыйфаты үсүен күрсәтә.

Татар телендә күптәннән кулланыла торган сүзләрнең яңа мәгънәләре көндәлек тормыштагы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә һәм фән-техниканың алга китүенә бәйле рәвештә үсеп чыга. Мондый мәгънәләрне икегә бүлеп карау уңайлы: 1) көнкүрештәге һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйләнгән мәгънә үзгәрешләре; 2) гадәти сүзләрне терминлаштыру нәтиҗәсендә туган өстәмә мәгънәләр.

Мәсәлән түбәндәге сүзләргә элек булган мәгънәләре янына яңа мәгънәләр өстәлгән (яңа мәгънәләр курсив белән бирелә): **баскыч** – 1) лестница; ступень, ступенька, трап; подножка, стремянка; 2) *давило*; **бөят** – 1) подхомутник, хомутина; 2) *спасательный пробковый круг;* **күләгә** – 1) тень, сень; 2) *зонтик*; **япкыч** – покрывало; *покрышка*; **ярлык** – 1) ярлык; 2) *квитанция, расписка, письменный пропуск;* 3) указ, царская грамота, *диплом* һ.б.

Узган гасыр башында (аеруча 1913 елгы сүзлек материалы буенча караганда) бер төркем сүзләрнең хәзерге телдә сакланмаган мәгънәләре дә теркәлгән. Мәсәлән, **ачык хат** – открытое письмо, *открытка* мәгънәләреннән хәзер исә *открытка* дигән предметны белдерү өчен рус сүзе үзе кулланыла башлаган. **Әрем** – репейник дип теркәлгән сүз хәзерге телдә *әрекмән, тигәнәк* дигән үсемлекләрне белдерә, ә *әрем – полынь* дип тәрҗемә ителә, бу сүз революциядән соң ук бүгенге телгә якын мәгънәдә конкретлаша башлаган була: *полынь, чернобыльник, нехворощь, эстрагон (даладагы)*. **Әрлән** – кроликъ дип теркәлгән, бу сүзнең мәгънәсе дә гасыр урталарына конкретлаша төшкән: *әрлән – хомяк* дип аталган кимерүче хайванны белдерә башлаган, ә *кролик – йорт куянын* аңлата һ.б. **Яшәрмәк** – күз яшьләнмәк – прослезиться, **юнәлмәк** – исправляться, поправиться мәгънәләре сакланмаган һ.б.

Татар халкы тормышындагы аерым гореф-гадәтләр белән бәйле кайбер сүзләр дә беренчел мәгънәләре югалып, башка төшенчә-күренешләрне атау өчен йөри башлаганнар: **биләм** – гуляние молодежи, ә узган гасыр уртасында *бездельное хождение*; **биләмче** – непосед, ә соңга таба *праздношатающийся, подворник, подворница* дигәнне аңлаткан. **Сыйрат күпере** – 1) радуга; 2) мост, проведенный по верованию мусульман над адом (мифический); причем он воображается тоньше волоска, острее сабли мәгънәләренең икенчесе генә калган, ә беренче мәгънәсен *салават күпере* сүзтезмәсе белдерә, аның да беренчел мәгънәсе *благословенный мост* дигәнгә туры килә икән. Сүзлек материалыннан аңлашылганча, **көндәш** – при многоженстве каждая жена по отношению к другой является *көндәш*; причем муж уделяет каждой жене известный день недели. Отсюда: көндәш = соучастница в использовании дней дигәнне аңлаткан, ә 1950 елгы сүзлектә бу сүз искергән тамгасы белән, *соперник, соперница* дип теркәлгән һ.б.

Татар теле лексикасына рус теленең йогынтысы төрлечә чагылыш таба. Рус һәм Европа телләреннән алынмалар кабул итү белән беррәттән, рус сүзләрен һәм сүзтезмәләрен татар теленә калькалаштыру юлы белән күчерә торган мөстәкыйль система да барлыкка килә. Бу очракта алынма сүзләр морфемага морфема туры килерлек итеп тәрҗемә ителә һәм татар теле материалында рус сүзләренең морфологик күчермәләре туа. Калькалаштырганда, чит сүзнең морфологик төзелеше һәм мотивировкасы кабул ителә: **әрчегеч** – очиститель; **әчеләткеч** – окислитель; **үсемлекләр дөньясы** – *растительный мир*, **эндәш билгесе** – восклицательный знак, **эш көче** – рабочая сила, **кызыл мал** – красный товар, мануфактура, **үрә сызык** – вертикальная линия, **төньяк балкышы** – северное сияние, **аеклык** – трезвость; **ишетелеш** – слышимость; **күптәнгелек** – давность, **белдермә** – извещение, уведомление, заявка, донесение, повестка, *объявление*, публикация, сообщение; **ирештермә** – донесение һ.б.

Нигезләрне кушу юлы белән кушма калькалар барлыкка килергә мөмкин. Бу вакытта рус телендәге кушма сүз үрнәгендә ике тамыр (нигез) кушыла: **аккойрык** (кош) – белохвост; **аккүз** (кош) – белоглазка; **акмуен** (кош) – белошейка; **акмыек** (бот.) – белоус; **алтөрән** – предплужник; **алтыкөнлек** – шестидневка; **алтыпочмак** – шестиугольник; **аюколак** (бот.) – медвежье ухо; **балашар** – медоед (птица); **балимәр** – медосос (птица); **башваткыч** – *головоломка*, шарада; **безкойрык** – шилохвост (птица); **бербуын** – одночлен (мат.); **бөҗәкашар** – насекомоядный; **өскорма** – надстройка; **өскуйма** – надставка; **өчаяк** – треножник; **сусалмалы** – водоналивной; **укъяфрак** – стрелолист (бот.); **үзагым, үзагыш** – самотек; **үзидарә** – самоуправление; **эшбашкаручы** – делопроизводитель һ.б. Кушма калькалар күбрәк зоология, биология фәннәренә караган терминнар арасында күп очрый; алар шактый уңышлы ясалганнар, зур күпчелеге хәзер дә гамәлдә, кайберләре төзелешләре ягыннан аз гына үзгәрешләр кичереп, телдә кулланылуларын дәвам итәләр. Мәсәлән, **азыктамыр** – корнеплоды, употребляемые в пищу хәзерге телдә *тамыразык*; **борынмөгез** – носорог түгел, ә *мөгезборын* һ.б. Бу сүзләрдә нигезләрне нәкъ рус телендәге тәртиптә урнаштыру татар теле өчен бик ук яңгырашлы түгел.

Диалектлар белән сөйләшләр әдәби телнең лексикасын үстерүдә ышанычлы чара булып тора. Әдәби телнең лексикасын баетуда диалекталь сүзләрне файдалану тел үсешен аңлы рәвештә көйләүгә керә [6, б.207]. Күренекле тел галиме М.З.Зәкиев тә әдәби телне баетуда диалектларның иң әһәмиятле чыганак булуларын ассызыклый [1, с.25].

Җәмгыять төзелешендәге революцион үзгәрешләрнең телгә ясаган җитди тәэсире халыкның территориаль һәм социаль пространствода күченүләре һәм аралаша башлаулары белән дә бәйләнгән. Төрле иҗтимагый һәм җирле диалект вәкилләре яңа тел шартларына килеп эләгә, аларның сөйләме чит сөйләм йогынтысын кичерә һәм үзләре дә башкаларның сөйләменә тәэсир итә. Мондый төрдәге процесслар телнең төрле яшәеш формаларының чикләре "йомшаруга" китерә. Аерым алганда, 1917 елгы һәм аннан соңгы вакыйгалар телнең халыкчан юнәлештә үсүен тизләтәләр. Бер яктан, зыялы сөйләмнең китапча формалары юкка чыга. Икенче яктан – "дөрес" (әдәби) сөйләмнең түбәнге чикләре көндәлек аралашу теле белән кушылып китә [5, с.152].

Әдәби телләрнең халыкка якынаюын, әдәби тел нормаларының халыкка якын нигезләрдә корылуын лексикада диалекталь сүзләрнең урыны да билгели. Илдә барган революцион үзгәрешләр әдәби телдә кайбер җирле сөйләм элементлары кулланыла башлауга юл ача. Халыкчан тел формалашкан чорда, әдәби телләргә телнең эчке сүз ясалышы һәм тышкы алынмалар нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүзләр белән бергә, җирле халыкның көнкүрешен, гадәтләрен, һөнәр-кәсеп үзенчәлекләрен чагылдырган бай диалекталь лексика да үтеп керә.

XX гасырның беренче яртысында чыккан татарча-русча сүзлекләрдәге лексик байлыкны барлап, тикшереп чыгу шуны күрсәтте: бу чор сүзлекләрендә диалекталь сүзләр шактый күп теркәлгән һәм алар арасында **лексик** диалек-

тизмнар өстенлек итә: *бадиян*, *җамаяк*, *кәнди*, *кагыт*, *кәлҗемә*, *котырчык*, *мәмәч*, *паңгы, инче*, *кач*, *келәү*, *куркылык, бабачы*, *җайдак*, *иранай*, *иркәк*, *кортка*, *сәвәләй* һ.б шундый тормыш көнкүрешнең төрле өлкәләренә караган сүзләр сүзлекләрдә урын алган. Аларның кайберләре әдәби телгә кереп киткән. Сүзлекләргә теркәлгән аерым сүзләрне карап үтү кызыклы булыр: **көленкәй** – жеребеночек, минзәлә сөйләшендә *көлөңкәй* диләр; **жумба** – налим сүзе сөйләшләрдә төрле төрдәге балыкларны атый: казан арты-балтач, казан арты-этнә сөйләшендә *җәен* балыгы (сом), Мамадыш якларында *чуртан* балыгын белдерә; **эргәзинбай** – подснежник чистай, хвалын сөйләшләрендә "кар чәчәге" дигән мәгънәдә йөри һ.б. **Кураз** – әтәч сүзе диалектларда "сугыш әтәче, сугышчан, усал әтәч"не белдерә, ул төрек телендә дә "хорус" вариантында сакланып калган.

Сүзлекләрдә урын алган лексик диалектизмнар арасында **семантик** дип аталган төре дә күзәтелә. Бу очракта сүз гомумхалык телендәге мәгънәсеннән аерыла, аларны диалекталь омонимиягә дә кертеп карыйлар. Язылышы белән әдәби телдәге сүзгә туры килгән, әмма башка мәгънә белдерә торган сүзләргә түбәндәге берәмлекләрне мисал итеп китерергә була: **атлама** – 1) скоба, 2) стропила, беренче мәгънәсе татар әдәби телендә дә кулланыла, "түбә кыегы" мәгънәсе Алабуга районында яшәүчеләр теленә хас; **җәйләү** сүзе хәзерге татар әдәби телендә терлекләрне авылдан читтә, яшеллек мул булган урында яшәтү өчен махсус корылган ферманы белдерә. Сүзлекләрдәге "блюдо, поднос, тарелка" мәгънәләре казан арты-керәшен сөйләшләрендә очрый; **җилле** сүзе хәзерге телдә җил исеп торган, җил көчле булган дигәнне аңлата, татарча-русча сүзлектәге "хороший" (хороший человек) мәгънәсе диалектларда да очрый, мәсәлән, Сарман, Зәй якларында "бик яхшы, җитез" дигәнне аңлата; хәзерге татар телендә билгеле бер хөкүмәте булган дәүләт, туып үскән җир-ватан төшенчәсен бирүче **ил** сүзе "село" мәгънәсендә аңлатмалы сүзлектә дә диалекталь сүз дип бирелә һ.б.

Диалекталь сүзләр арасында әдәби формалардан аваз составы белән генә аерылып торган берәмлекләр дә бар. Аларны **фонетик диалектизмнар** дип атыйлар. Мондый сүзләр әдәби тел сүзләреннән сузыклар һәм тартыклар өлкәсендәге үзгәрешләр белән аерылып торалар. Мәсәлән, **й-ләштерү** (әдәби телдәге [ж] авазы урынына [й] әйтү, язу): *йеб*, *йебәрмәк*, *йебетмәк* (1913, б.204), *йебешек*, *йеде*, *йелек*, *йемеш*, *йепсә* һ.б.; **җ-ләштерү** (әдәби телдәге [й] авазы урынына [ж] авазы әйтү, язу): *җавым*, *җагымлы*, *җак*, *җаңгыр*, *җар*, *җара*, *җарма* һ.б. Калган аваз чиратлашулары закончалыклы төстә түгел, бер-ике сүздә генә очрый. Түбәндәге сүзләрне дә җирле сөйләшләрдә кайбер аваз үзгәрешләренә дучар булганнар дияргә була: *азбар*, әдәби телдә *абзар* – метатеза күренеше; *асат – ансат* сүзендә диэреза күренеше (тартык авазның төшеп калуы) күзәтелә; *борам*, рус телендә *паром; искәү*, әдәби телдә *иснәү; кауга*, әдәби телдә *гауга*, к ~ г чиратлашуы диалекталь һәм әдәби сүзләр арасында шактый күп сүзләрдә очрый; *каулау – куалау* сүзенең диалекталь варианты – шулай ук метатеза күренеше дияргә була; *кач – хач* (крест) сүзен белдерә, х ~ к чиратлашулары да күп кенә диалекталь сүзләрдә очрый; *лакша – лапша* сүзенең фонетик үзгәргән рәвеше һ.б.

XX гасырның беренче яртысында басылган татарча-русча сүзлекләр буенча татар теле лексикасының үз ресурслары нигезендә үсешен күзәтеп чыгу түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирде.

1. Сүзлекләргә теркәлгән мисаллар XX гасырның беренче яртысында телнең үз сүзләреннән төрле юллар белән яңа сүзләр, аерым алганда төрле фәннәргә караган атамаларның күпләп ясалуын күрсәтә. Телнең үз мөмкинлекләреннән файдаланып ясалган сүзләрнең зур өлеше хәзерге татар телендә дә актив кулланыла. Татар сүзләреннән кушымчалар ярдәмендә дә, синтаксик юл белән дә яңа сүзләр күп ясалган. Болар барысы да татар теленең сүз ясау чаралары һәм ысуллары барлык чорларда да актив булуын исбатлый.

2. Сүзләрдәге төрле мәгънәләр, мәгънә төсмерләре барлыкка килү җәмгыятьтә барган һәртөрле үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнгән. Сүзлекләрдә мондый мисалларны да күпләп күзәтергә мөмкин. Бу вакытта аерым сүзләрнең конкрет мәгънәсе гомумиләшкән, абстракт характер алган; ә кайберләре үзләренең беренчел мәгънәләрен югалтып, яңа мәгънәләрдә теркәлеп калганнар; бер төркем сүзләр мәгънәләре киңәю нәтиҗәсендә термин буларак кулланыла башлаганнар. Шул рәвешчә, сүзләрдәге семантик үзгәрешләр телнең лексик составында сизелерлек эз калдырган.

3. XX гасырның беренче яртысында басылган сүзлекләрдә калькалаштыру юлы белән ясалган берәмлекләр дә күп теркәлгән. Бу лексемалар аңлы рәвештә, әдәби телдәге язма иҗат процессында, бигрәк тә төрле фәннәрне татарчалаштырганда, тәрҗемә нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Гасыр башында мондый сүзләр артык күп түгел, ә 30-40 нчы еллар лексикасында калькалар аеруча күп күзәтелә. Бу – революциядән соң татар теленең халыкчан нигезләрдә үсәргә омтылуын дәлилли. Телнең лексикасын бу юл белән үстерүнең уңай ягы шул була: калькалаштыру юлы

татар теленең үз сүз ясау чараларын активлаштырырга ярдәм итә.

4. XX гасырның беренче яртысындагы татар әдәби телендә диалекталь лексика да шактый урын тоткан. Диалектизмнар арасында предметны, күренешләрне белдерүче сүзләр аеруча күп. Шулай ук төрле сыйфатлау сүзләре, фигыльләр дә шактый. Диалекталь сүзләрнең күләме буенча фикер йөрткәндә, 1913 елгы сүзлектә алар азрак, ә революциядән соң дөнья күргән (1927, 1931) сүзлекләрдә җирле сөйләм берәмлекләре ешрак очрый. Бу революция тәэсирендә әдәби телләрнең халыкчанлашуы белән аңлатылырга мөмкин. 1950 елгы сүзлектә исә диалекталь элементларның кими башлавы күзәтелә. Сүзлекләрдә урын алган диалекталь берәмлекләр күбрәк урта диалект сөйләшләренә карый. Алар арасында саф лексик диалектизмнар күбрәк, шулай ук кайбер җирле фонетик үзенчәлекләр дә урын алган, аларның күбесе җ-ләштерү һәм й-ләштерү күренешенә карый, шулай ук башка аваз чиратлашулары да, аваз үзгәрешләре дә күзәтелә. Семантик диалектизмнар да очрый, морфологик диалектизмнарны юк дияргә мөмкин. Сүзлекләрдәге лексик материалны тикшерү барышында сүзлекләргә диалекталь сүзләрне теркәүнең дә кайбер сәбәпләрен ачыкларга мөмкин булды: беренчедән, бу җирле сөйләм сүзләрен активлаштыру, әдәби телне баету теләге белән эшләнгән; икенчедән, сүзлекләрдән төрле диалект һәм сөйләш вәкилләренең куллану ихтималы күздә тотылган; сүзлекләр төзелгән чорда әдәби тел һәм диалектлар чиге билгеләнеп бетмәгән булган; авторларның билгеле бер диалект, сөйләш вәкиле булу лөгатьлеккә сүзләр сайлаганда шулай ук тәэсир иткән булырга мөмкин; сүзлекләр төзелгән чорда махсус эшкәртелгән лөгатьлек булмау сәбәпле, сүзлек төзүчеләр сүзләрне халык арасына чыгып, халыкның җанлы сөйләменнән туплаганнар; сүзлекләргә диалекталь сүзләрне теркәү авторларның әдәби телне начар белүләрен күрсәтми, чөнки күпчелек диалекталь элементлар янында аларның әдәби телдәге синонимнары бирелгән яки шуларга җибәрелгән; бу эштә татар вакытлы матбугаты үсү дә үз өлешен керткән: алар әдәби телгә төрле диалекталь, гади сөйләм сүзләре үтеп керүгә юл ачкан.

Татар теле тарихында XX гасырның беренче яртысы бары тик билгеле бер дәрәҗәдә генә шартлы "чик"не тәшкил итә, ул тарихи яктан ачыграк күренеп тора. 1900-1950 нче еллар – Россия тарихында әһәмиятле этап, зур иҗтимагый-икътисадый үзгәрешләр дәвере, халык хуҗалыгын үзгәртеп кору вакыты. Икътисадый һәм иҗтимагый процессларга китерүче сәяси вакыйгалар бу чорда күп санлы һәм киң колачлы. Әдәби телнең сүзлек составында барган үзгәрешләр әлеге күренешләрне ачык чагылдыра.

Кешелек тарихында беренче социалистик дәүләт барлыкка килү һәм үсә башлау татар теле лексикасының да алга таба кызу темплар белән яңару һәм үзгәрүенә сәбәп була. Яңа матди, иҗтимагый һәм рухи тормыш шартларында татар теленең сүзлек составы да күзгә күренеп үсә башлый. Аның сүзлек байлыгы, тормышның төрле өлкәләрендә барган яңа күренешләр кебек үк, сизелерлек арта: иҗтимагый-сәяси, икътисадый, фәнни, техник һәм көнкүрештәге яңа күренешләр яңа атамалар таләп итә. Татар теле лексикасының бу чордагы үсешен билгели торган төп тенденция – гамәлдә булган барлык лексик чараларны, нинди чыганактан булуларына карамастан, берләштерүдән гыйбарәт. Татарча-русча сүзлекләрдә бу тенденция нәтиҗәләре аеруча ачык һәм тулы чагылыш таба.

* * * * * * * * * *

1. Закиев М.З. Некоторые вопросы развития татарского литературного языка // Вопросы татарского языкознания. Казань, 1965.
2. Будагов Р.А. Проблемы развития языка. М.-Л., 1965.
3. Валгина Н.С. Активные процессы в современном русском языке. М., 2001.
4. Шмелев Д.Н. О некоторых тенденциях развития современной русской лексики // Развитие лексики современного русского языка. М., 1965.
5. Мечковская Н.Б. Социальная лингвистика. М., 1996.
6. Татар грамматикасы: Өч томда. М., Казан, 1998. Т.1.
7. Рамазанов Ш. Совет чорында татар әдәби теленең үсеше (Татарстанның 25 еллыгына багышлана) // Совет әдәбияты. 1945. №6. Б.87-97.

# INNER RESOURCES OF THE TATAR LEXICON DEVELOPMENT

**R.S.Nurmukhametova**

The article deals with the investigation of the Tatar literary language vocabulary in the first part of the XX century. The internal reasons for it's development such as word-formation, meaning expansion of a word, loan translation, dialect usage are considered. Conclusions are proved by materials of Tatar-Russian dictionaries of the given period.